ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Кече
Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» ноябрь 2024 ел № 16

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге составына керүче Кече Урыссу торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 22 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Кече Урыссу авылы, Совет урамы, 21а адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Россия Армиясе сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнардан тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүдән үзара салым кертүгә ризамы?:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пунктында Совет урамында юл-урам челтәрен төзү, ремонтлау (асфальт салу, вак таш салу, материаллар, җайланмалар сатып алу, транспорт чыгымнары, эшләр өчен шартнамә буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына Кече Урыссу торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.),

Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев